РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
СОВЕТ
ЧЕРЕМШАНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
ул. Советская, д.32, село Черемшан, 423100

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЧИРМЕШӘН МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ
СОВЕТЫ
Совет урамы, 32е йорт, Чирмешән авылы, 423100

тел./факс +7(84396) 2-59-00, email: cheremshan@tatar.ru, http://cheremshan.tatarstan.ru

02.11.2021 ел №69

Татарстан Республикасы
Чирмешән муниципаль районы Советы
**КАРАРЫ**

Чирмешән муниципаль районы Советының «Татарстан Республикасы «Чирмешән муниципаль районы» муниципаль берәмлеге милкендә булган, кече һәм урта эшкуарлык субъектларына биләүгә һәм (яки) файдалануга тапшыру өчен билгеләнгән муниципаль милек исемлеген формалаштыру, алып бару һәм бастырып чыгару тәртибен раслау турында» 2019 елның 18 июлендәге 239 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясендә кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү турында» Федераль законга һәм «Россия Федерациясендә кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү турында» Федераль законга үзгәрешләр кертү хакында» Федераль законның 1 һәм 2 статьяларына үзгәрешләр кертү турында» 2020 елның 8 июнендәге 169-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, ярдәм алучы кече һәм урта эшкуарлык субъектларының бердәм реестрын формалаштыру максатларында, шәхси эшмәкәрләр булмаган һәм «Һөнәри керемгә салым» махсус салым режимын кулланучы физик затларга (үзмәшгуль гражданнар) ярдәм чаралары күрсәтү максатларында, Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Советы **КАРАР ИТТЕ:**

1. Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Советының 2019 елның 18 июлендәге 239 номерлы карарына 1 нче кушымта белән расланган, Татарстан Республикасы «Чирмешән муниципаль районы» муниципаль берәмлеге милкендә булган, кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына бирү һәм (яки) файдалануга тапшыру өчен билгеләнгән муниципаль милек исемлеген формалаштыру, алып бару һәм бастырып чыгару тәртибенә түбәндәге эчтәлекле 1.6 пункт өстәргә: «1.6 Исемлеккә кертелгән, Чирмешән муниципаль районы милкендә булган, өченче затлар хокукларыннан (кече һәм урта эшкуарлык субъектларының

мөлкәти хокукларыннан тыш) ирекле һәм кече һәм урта эшкуарлык субъектларына һәм кече һәм урта эшкуарлык субъектларына ярдәм инфраструктурасын барлыкка китерүче оешмаларга бирү өчен билгеләнгән мөлкәт, шулай ук индивидуаль эшкуарлар булмаган һәм «Һөнәри керемгә салым» махсус салым режимын кулланучы физик затларга бирелергә мөмкин дип билгеләргә.

2. Әлеге карарны «Безнең Чирмешән»-(«Наш Черемшан») газетасында, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районының Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тоту район Советының икътисади сәясәт һәм бюджет буенча даими комиссиясенә йөкләнә.

Муниципаль район башлыгы,
Совет рәисе Ф.М. Дәүләтшин